КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 декабрь г.Казань № 1615

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 741 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1165 нче; 2021 ел, 11 май, 325 нче; 2021 ел, 31 май, 416 нчы; 2021 ел, 12 июнь, 446 нчы; 2022 ел, 3 июнь, 514 нче; 2022 ел, 11 июнь, 550 нче; 2022 ел, 20 декабрь, 1374 нче; 2023 ел, 25 май, 639 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Тиешле финанс елына Министрлык тарафыннан расланган әлеге түләүләрне алучыларның җыелма исемлеге нигезендә гражданнарга социаль түләүләр бирү өчен тиешле финанс елына i-муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансферт күләме (Vi) түбәндәге формула буенча исәпләнә:»;

дүртенче абзацта «агымдагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «агымдагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «агымдагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта татар текстында «торак йорт» сүзләрен «торак йортның 30 процenttan артыгы» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «агымдагы финанс елына Министрлык тарафыннан расланган социаль түләүләрне алучыларның төгәлләштерелгән җыелма исемлеге» сүзләрен «тиешле финанс елына Министрлык тарафыннан расланган социаль түләүләрне алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктның «б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

$13^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$13^1$. Тиешле финанс елына Министрлык тарафыннан расланган социаль түләүләрне алучыларның җыелма исемлегенә үзгәрешләр кертелгән очракта, агымдагы елның 1 декабренә кадәр Министрлык муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлүгә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалануның түбәндәге нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү нигезендә бәяләнә – авыл территорияләрендә яшәүче яисә авыл территорияләрендә даими яшәргә теләк белдерүче һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы, социаль түләүләр бирелгән гражданнар тарафыннан торак төзү (сатып алу) гамәлгә ашырылган.»;

18 пунктта «15» саннарын «17» саннарына алмаштырырга, «1 июненә» сүзләрен «15 маена» сүзләренә алмаштырырга, «башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре» сүзләрен «субсидия бирү кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Тиешле финанс елына i муниципаль берәмлеге бюджетына субсидия күләме (Vi) түбәндәге формула буенча билгеләнә:»;

дүртенче абзацта «чираттагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «чираттагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма

исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «чираттагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктның «б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге Министрлык тарафыннан субсидиядән файдалануның түбәндәге нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү нигезендә бәяләнә – гражданнарга бирелә торган торак төзелеше (сатып алу) гамәлгә ашырылган, кв.метр.»;

18 пунктта «15» саннарын «17» саннарына алмаштырырга, «1 июненә» сүзләрен «15 маена» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

10 пунктның «б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге ел саен Министрлык тарафыннан субсидиядән файдалануның түбәндәге нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү нигезендә бәяләнә – проектлар гамәлгә ашырылды, берәмлек.»;

18 пунктта «15» саннарын «17» саннарына алмаштырырга, «1 июненә» сүзләрен «15 маена» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен формалаштыру, раслау һәм аларга үзгәреш кертү һәм авыл территорияләрендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибендә:

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Җирле үзидарә органнары ел саен, чираттагы финанс елына кадәрге елның 1 февраленә кадәр, социаль түләүләрдән файдаланып, торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнарга әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча гариза бирү юлы белән чираттагы финанс елына һәм план чорына Дәүләт программасы кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларында катнашуга үз ризалыгын (алга таба – чараларда катнашуга ризалык) раслау зарурлыгы, шулай ук Нигезләмәнең 21 пунктында һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны яңарту зарурлыгы турында хәбәр итү эшен оештыралар. Гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамәнең фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирә торган ысул белән гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

15 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Граждан тарафыннан чираттагы финанс елына кадәрге елның 1 маена кадәр әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә чараларда катнашуга ризалык бирү расланмаган яисә яңартылган документлар тапшырылмаган, шулай ук яңартылган

документлар буенча Нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән социаль түләү бирү шартларына гражданның туры килмәве ачыкланган очракта, җирле үзидарә органы аны чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль түләүләрне кулланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенең чираттагы төркеменә кертми һәм, чараларда катнашуга ризалыкны раслау өчен әлеге пунктта билгеләнгән срок тәмамланган көннән соң 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, гражданга әлеге исемлеккә кертелмәскә тиешлеге турында язма хәбәрнамә әзерли һәм җибәрә.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Җирле үзидарә органы ел саен, чираттагы финанс елына кадәрге елның 15 маена кадәр, гариза бирү һәм социаль түләүләрне беренче чиратта бирү датасы буенча хронологик тәртиптә чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлеген, гариза бирү һәм социаль түләүләрне беренче чиратта бирү датасы буенча чиратлылыкны исәпкә алып, әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта формасы буенча формалаштыра һәм аны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) җибәрә.

Әлеге исемлеккә бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча чираттагы финанс елына кадәрге елның 1 апреленә кадәр гариза биргән һәм чираттагы финанс елына кадәрге елның 1 маена кадәр чараларда катнашуга ризалыкны раслаган, әлеге Тәртипнең 12 пунктында билгеләнгән исемлеккә кертүдән баш тарту өчен нигез булмаган гражданнар кертелә.»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән исемлекләр нигезендә Министрлык әлеге Тәртипнең 7 нче кушымтасында бирелгән форма буенча чираттагы финанс елына социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшырту чараларында катнашучыларның җыелма исемлеген (алга таба – катнашучыларның җыелма исемлеге) раслый һәм чираттагы финанс елына катнашучыларның җыелма исемлеге формасы кебек форма буенча, Нигезләмәнең 7, 8 пунктлары нигезендә социаль түләүләрне беренче чиратта бирү һәм гариза бирү датасы буенча хронологик тәртиптә чиратны исәпкә алып, план чорына катнашучыларның җыелма исемлеген төзи.»;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Татарстан Республикасы бюджетында авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чаралары өчен каралган чираттагы финанс елына федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын исәпкә алып, Министрлык, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы кабул ителгән көннән соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, чираттагы финанс елына катнашучыларның җыелма исемлегенә үзгәреш кертә һәм чираттагы финанс елына катнашучыларның җыелма исемлеге формасы кебек форма буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә чират тәртибендә чираттагы финанс елына социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеген раслый һәм гражданнарга мәгълүматны җиткерү өчен җирле үзидарә органнарына кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Нигезләмәнең 24 пункты нигезендә социаль түләүләр алучыларның җыелма

исемлегенә социаль түләүләрне өлешчә бирү шартларында бер социаль түләү алучы (аның ризалыгы белән) кертелә. Чираттагы финанс елына катнашучыларның киләсе җыелма исемлеген төзегәндә әлеге социаль түләү алучы әлеге исемлеккә социаль түләүләрнең калган өлешен бирү өчен 1 нче номер итеп кертелә.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чаралары өчен агымдагы финанс елында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына ассигнованиеләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы арттырылган очракта, Министрлык, Татарстан Республикасы бюджетында өстәмә каралган акчаларны исәпкә алып, чират тәртибендә катнашучыларның җыелма исемлегеннән чараларда катнашучыларны кертү өлешендә социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлегенә үзгәреш кертә һәм гражданнарга мәгълүматны җиткерү өчен җирле үзидарә органнарына кабул ителгән карар турында хәбәр итә.»;

21 – 25 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

25[1] пунктта:

беренче абзацта «Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елына расланган төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «тиешле финанс елына социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы мөрәҗәгате нигезендә, кирәк булганда, Министрлык агымдагы финанс елының 1 ноябренә кадәр янга калган акча суммасы күләмендә җыелма исемлектән чираттагы чарада катнашучыны кертү өлешендә социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлегенә үзгәреш кертә һәм муниципаль берәмлекләр арасында акчаны яңадан бүлү буенча тәкъдим кертә.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Социаль түләүләр алучыларның расланган исемлеге нигезендә Министрлык әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә форма буенча таныклыкларны рәсмиләштерә.

Таныклыклар рәсмиләштерелә торган гражданнар Министрлыкның рәсми соравы буенча агымдагы датага әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча мәгълүмат бирә.»;

39 пунктта «25» саннарын «20» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2, 3, 7 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру, раслау һәм аларга үзгәреш кертүтәртибендә:

12 пунктта «торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләре» сүзләрен «чараларда катнашучылар исемлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән исемлекләр тапшырылган датадан 30 календарь көн эчендә әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча чираттагы финанс елына чараларда катнашучыларның җыелма исемлеген раслый, чираттагы финанс

елына чараларда катнашучыларның җыелма исемлеге формасы кебек форма буенча план чорына чараларда катнашучыларның җыелма исемлеген чараларда катнашучыларның гаризаларын бирү датасы буенча хронологик эзлеклелекне исәпкә алып төзи һәм чираттагы финанс елына чараларда катнашучыларның җыелма исемлегенә кертелгән чараларда катнашучыларның исәпкә алу эшләрен соратып ала.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы бюджетында торак урыны наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзүгә (сатып алуга) каралган чираттагы финанс елына федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын исәпкә алып, Министрлык, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы кабул ителгән көннән соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, чираттагы финанс елына чараларда катнашучыларның җыелма исемлегенә үзгәреш кертә һәм чираттагы финанс елына чараларда катнашучыларның җыелма исемлеге формасы кебек форма буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә чират тәртибендә чираттагы финанс елына торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлеген раслый һәм гражданнарга мәгълүматны җиткерү өчен җирле үзидарә органнарына кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Әгәр субсидия күләме чираттагы финанс елына торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлегенә кертелергә тиешле бер чараларда катнашучы өчен торак төзелешенең (сатып алуның) исәп-хисап кыйммәтенең 80 проценты күләмендә субсидиянең тулы күләмен бирү өчен җитәрлек булмаса, мондый субсидия алучы өлешчә субсидия бирү шартларында исемлеккә (аның ризалыгы белән) кертелә. Торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның киләсе җыелма исемлеген төзегәндә, мондый чараларда катнашучы субсидиянең калган өлешен бирү өчен исемлеккә 1 нче булып кертелә.

Торак урыны наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) өчен агымдагы финанс елында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына ассигнованиеләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы арттырылган очракта, Министрлык, Татарстан Республикасы бюджетында өстәмә каралган акчаларны исәпкә алып, чират тәртибендә катнашучыларның җыелма исемлегеннән чараларда катнашучыларны кертү өлешендә чираттагы финанс елына торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлегенә үзгәреш кертә һәм гражданнарга мәгълүматны җиткерү өчен җирле үзидарә органнарына кабул ителгән карар турында хәбәр итә.»;

16 – 19 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктта:

беренче абзацта «төгәлләштерелгән җыелма исемлек» сүзләрен «торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы мөрәҗәгате нигезендә, кирәк булганда, Министрлык агымдагы финанс елының 1 ноябренә кадәр янга калган акча суммасы күләмендә катнашучыларның җыелма исемлегеннән чараларда катнашучыларны чират тәртибендә кертү өлешендә торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак

алучыларның җыелма исемлегенә үзгәреш кертә һәм муниципаль берәмлекләр арасында акчаны яңадан бүлү буенча тәкъдим кертә.»;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипкә 2, 3, 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин